## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Кушкүл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**26 октябрь, 2019** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 23 октябрендә 13 сәгатьтә, 2019 елның 26 октябрендә 15 сәгатьтә, этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Кушкүл торак пунктында теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме? » соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
-торак пунктның чүплекләре территорияләрен чистарту;
б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау.»

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 74 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -41, бу 53 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:
"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 41 катнашучы тавыш бирде;
"Юк" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:
1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Кушкүл торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.
2. «Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Кушкүл торак

пунктында теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме? соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

-торак пунктның чүплекләре территорияләрен чистарту;

б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау.»- соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башлыгы С.П.Матвеева